ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ
БАШ ВЕТЕРИНАРИЯ ИДАРӘСЕ

Боерык

2015 елның 19 гыйнвары № 6-п

“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең Региональ дәүләт ветеринария күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функцияләрен башкаруның административ регламентын раслау турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең 2013 елның 27 маендагы 165-п номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең норматив хокукый актларын федераль законнарга туры китерү максатларында БОЕРЫК БИРӘМ:

1. “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең Региональ дәүләт ветеринария күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функцияләрен башкаруның административ регламентын раслау турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең 2013 елның 27 маендагы 165-п номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Ветеринария турында” 1993 елның 14 маендагы 4979-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында” 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон, “Татарстан Республикасында ветеринария эше турында” 1993 елның 13 июлендәге 1934-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 31 декабрендәге 1192 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт функцияләрен башкаруның административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 16 августындагы 563 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында региональ дәүләт ветеринария күзәтчелеге турында нигезләмә буенча һәм “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе мәсьәләләре” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 10 мартындагы 202 номерлы карары белән расланган

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе турында нигезләмәдә каралганча, БОЕРЫК БИРӘМ:”.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең 2013 елның 27 маендагы 165-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең Региональ дәүләт ветеринария күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен башкаруның административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 пунктта уникенче абзацны төшереп калдырырга;

1.3 пунктка, түбәндәге редакциядә бәян итеп, яңа абзац өстәргә:

“Татарстан Республикасында региональ дәүләт ветеринария күзәтчелеге турында нигезләмәне раслау хакында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 16 августындагы 563 номерлы карары (Сборник постановлений и распоряжений Кабинета Министров Республики Татарстан и нормативных актов республиканских органов исполнительной власти, 23.08. 2013, № 63, 1988 ст.).”;

1.6.2 пунктның 8 пунктчасында “юридик һәм физик затларның” сүзләрен “гражданнарның, шул исәптән индивидуаль эшкуарларның, юридик затларның” сүзләренә алмаштырырга;

1.7.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә:

“5) Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилне яки Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилне тикшерүдә катнашуга җәлеп итәргә.”;

2.2.1 пунктның өченче абзацында “(башлык урынбасары)” сүзләрен төшереп калдырырга;

2.2.1 пунктның өченче абзацында “кече предприятиеләргә” сүзләреннән соң “иң күбе илле сәгатькә” сүзләрен өстәргә;

2.5 пунктның 2 пунктчасында “294 номерлы Федераль закон” сүзләрен “294-ФЗ номерлы Федераль закон” сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлекнең 1 таблицасында “Учреждениеләр, предприятиеләр һәм оешмалар хезмәткәрләренә санитария-гигиена киемнәрен, санитария аяк киемен һәм санитария әйберләрен түләүсез бирү нормасы” СССР Сәламәтлек саклау министрлыгының 1988 елның 29 гыйнварындагы 65 номерлы боерыгы” сүзләрен “Сәламәтлек саклау учреждениеләре, предприятиеләре һәм оешмалары хезмәткәрләренә санитария-гигиена киемнәрен, санитария аяк киемен һәм санитария әйберләрен түләүсез бирүнең “Махсус киемне, махсус аяк киемен һәм башка индивидуаль саклану чараларын түләүсез бирүнең тармак нормаларын, шулай ук санитария киеме һәм санитария аяк киеме нормаларын кертү турында” СССР Сәламәтлек саклау министрлыгының 1988 елның 29 гыйнварындагы 65 номерлы боерыгы белән расланган нормасы” сүзләренә алмаштырырга;

5 бүлекнең дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан эшчәнлекне гамәлгә ашырганда куелган барлык мәҗбүри таләпләрне үтәү планлы тикшерүнең предметы булып тора”;

5.4.6 пунктның беренче абзацында “электрон цифрлы имза” сүзләрен “көчәйтелгән квалификацияле электрон имза” сүзләренә алмаштырырга;

7.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“7.3. Судка кадәр (судтан тыш) шикаятьне карауны туктатып тору һәм кире кагу өчен нигезләр каралмаган.

Шикаятькә йә шикаятьтә куелган мәсьәләнең асылы буенча түбәндәге очракларда җавап бирелми:

- язмача шикаятьтә аны юллаучы гариза бирүченең фамилиясе яисә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы күрсәтелмәгән булса (әгәр күрсәтелгән шикаятьтә хокукка каршы әзерләнә, кылына яисә кылынган гамәл турында, шулай ук аны әзерләүче, кылучы яисә кылган зат турында белешмәләр булса, шикаять тиешле компетенциясе булган дәүләт органына җибәрелергә тиеш);

- шикаятьтә әдәпсез гыйбарәләр йә хурлый торган гыйбарәләр, вазыйфаи затның, шулай ук аның гаилә әгъзаларының гомеренә, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янаулар булса (мондый шикаятьне юллаган гариза бирүчегә хокукны артыгыннан кирәк куллануның ярамаганлыгы турында хәбәр итәргә хокуклы);

- язмача шикаятьнең тексты укырлык булмаган очракта (мондый шикаять аны карау өчен тиешле компетенциясе булган дәүләт органына яисә вазыйфаи затка җибәрелми, бу хакта шикаять юллаган гариза бирүчегә, әгәр аның фамилиясе һәм почта адресы укырлык булса, шикаятьне теркәгән көннән алып җиде көн эчендә хәбәр ителә);

- язмача шикаятьтә бәян ителгән бердәнбер мәсьәлә буенча элек җибәрелгән шикаятьләргә бәйле рәвештә әлеге мәсьәләнең асылы буенча гариза бирүчегә күп тапкыр язмача җавап бирелгән булса һәм шикаятьтә аның буенча яңа дәлилләр китерелмәсә һәм шартлар күрсәтелмәсә (бу шикаять һәм элек җибәрелгән шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенә яисә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең бер үк вазыйфаи затына юлланган булса, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе башлыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең вазыйфаи заты йә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең вәкаләтле заты чираттагы шикаятьнең нигезсез булуы һәм гариза бирүче белән шушы мәсьәлә буенча хатлар язышуны туктату турында карар кабул итәргә хокуклы. Бу карар хакында шикаятьне юллаган гариза бирүчегә хәбәр ителә);

- шикаятьтә куелган мәсьәләнең асылы буенча җавап федераль закон белән саклanучы дәүләт серен һәм башка серне тәшкил итә торган белешмәләрне фаш итүдән башка бирелә алмаса (шикаятьне юллаган гариза бирүчегә күрсәтелгән белешмәләрне фаш итүнең ярамаганлыгына бәйле рәвештә шикаятьтә куелган мәсьәләнең асылы буенча җавап бирү мөмкинлеге булмавы турында хәбәр ителә). Шикаятьтә куелган мәсьәләләрнең асылы

буенча җавап бирү мөмкинлеген бирми торган сәбәпләр бетерелсә, гариза бирүче шикаятьне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенә яңадан җибәрергә хокуклы.

Суд карарына шикаять белдерелә торган шикаять теркәгән көннән алып җиде көн эчендә, шушы суд карарына шикаять белдерү тәртибен аңлатып, шикаять юллаган гариза бирүчегә кире кайтарыла.

Татарстан Республикасы Министрлар
Кабинетының Баш ветеринария
идарәсе башлыгы А.Г. Хисаметдинов